| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет<br>Майскогорского сельского поселения<br>Нижнекамского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Түбән Кама муниципаль районы<br>Майская Горка авыл жирлеге<br>Советы |
|---|---|
| 423565, Нижнекамский район,<br>п. Трудовой, ул. Школьная, 11 | 423565, Түбән Кама районы, Трудовой<br>поселогы, Мэктэп урамы, 11 |

тел./факс (8555) 33-57-17, электронный адрес: Mayskogorsko.sp@tatar.ru, сайт: www. majskogorskoe-sp.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 25 июленнән № 14

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Майская Горка авыл җирлеге Советының
2014 елның 30 октябрендәге
20 номерлы карарына
үзгәрешләр кертүтурында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Майская Горка авыл җирлеге Советы карарбирә:

1. Майская Горка авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 октябрендәге 20 номерлы карары белән расланган «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 7 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) белешмә бирү чорына кадәрге календарь ел эчендә (алга таба – хисап чоры) үзе, анынҗире (хатыны) һәм (яки) балигъ булмаган балаларыбашкарган җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (катнашу өлеше, оешмаларның устав (склад) капиталларында пайлар)

алуда һәр килешү буенча үзенең чыгымнары, шулай ук аның ире (хатыны) һәм (яки) балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алар хисабына алыш-бирешләр башкарылган акча алу чыганаклары турында.».

1.2. Нигезләмәнең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тәкъдим ителгәнҗир кишәрлеген, башка күчемсез милек объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (катнашу өлеше, оешмаларның устав (склад) капиталларында пайларны) сатып алу буенчаалар хисабына алыш-бирешләр башкарылган (алыш-биреш башкарылган) акча алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда муниципаль вазыйфаяисә муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыручы (биләүче) затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, федераль законнар нигезендә урнаштырыла.».

1.3. Нигезләмәнең 16 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «в» пунктчасында каралган мәгълүматларны тапшыру буенча бурычны муниципаль вазыйфаны биләче зат тарафыннан башкармау хокук бозу булып тора. Күрсәтелгән хокук бозуны кылган зат биләгән вазыйфасыннан билгеләнгән тәртиптә азат ителергә тиеш.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затның чыгымнарын, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшерүне гамәлгә ашыру барышында әлеге зат чыгымнары, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары гомуми керемнәренә туры килмәүне раслаучы хәлләр ачыкланган очракта, чыгымнарны тикшерүне гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынган материаллар ул тәмамланганнан соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына җибәрелә.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затның чыгымнарын, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшерүне гамәлгә ашыру барышында җинаять, административ яки башка хокук бозу билгеләре ачыкланган очракта, чыгымнарны тикшерүне гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынган материаллар ул тәмамланганнан соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан дәүләт органнарына аларның компетенцияләре нигезендә җибәрелә».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Майская Горка авыл җирлеге башлыгы — С.Н. Шумилов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НИЖНЕКАМСКИЙ РАЙОН ОГРН 1061651024104 МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «СОВЕТ МАЙСКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ИНН 1651045243 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА РАЙОНЫ